# Татарстан Республикасы
# ЗАКОНЫ

**"Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында" Татарстан Республикасы Законына һәм Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 2.3, 8.1 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2010 елның 9 июнендә
кабул ителде

**1 статья**

"Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында" 2000 елның 3 мартындагы 95 номерлы Татарстан Республикасы Законына (2003 елның 9 августындагы 32-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2000, № 3 (3); 2003, № 8; 2008, № 11 (III өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 10 статьяны үз көчен югалткан дип танырга;

2) 11 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:
"11 статья. **Вәкаләтле вәкил өчен чикләүләр**

Вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затлар өчен билгеләнгән чикләүләрне федераль законнар нигезендә үтәргә тиеш.";

3) 12 статьяда:
а) 1 өлештә:
5 пунктта "әлеге Законда" сүзләрен "федераль законнарда" сүзләренә алмаштырырга;
6 пунктны үз көчен югалткан дип танырга;
б) 2 өлештә "йә даими яшәү өчен Татарстан Республикасыннан читкә китүе" сүзләрен төшереп калдырырга;
в) түбәндәге эчтәлекле 5 өлеш өстәргә:

"5. Вәкаләтле вәкил вәкаләтләре әлеге статьяның 1 һәм 2 өлешләрендә күрсәтелгән нигезләр буенча вакытыннан алда туктатылган очракта, аның вәкаләтләрен, яңа Вәкаләтле вәкил сайланганчы һәм вазыйфасына керешкәнче, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил башкара.";

4) 14 статьяда:

а) 1 өлештә:

1 пунктка "дәүләт органнарына" сүзләре алдыннан "Татарстан Республикасы" сүзләрен өстәргә;

2 һәм 3 пунктларга "дәүләт органнарының" сүзләре алдыннан "Татарстан Республикасы" сүзләрен өстәргә;

4 пунктта "дәүләт яисә муниципаль хезмәткәрләр" сүзләрен "Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре, муниципаль хезмәткәрләр" сүзләренә алмаштырырга;

5 һәм 6 пунктларга "дәүләт органнарына" сүзләре алдыннан "Татарстан Республикасы" сүзләрен өстәргә;

б) 2 өлешкә "дәүләт органнарының" сүзләре алдыннан "Татарстан Республикасы" сүзләрен өстәргә;

в) 3 өлешкә "дәүләт органнары" сүзләре алдыннан "Татарстан Республикасы" сүзләрен өстәргә;

5) 16 статьяның 1 өлешенә "дәүләт органнарының" сүзләре алдыннан "Татарстан Республикасы" сүзләрен өстәргә; "дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләрнең" сүзләрен "Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең" сүзләренә алмаштырырга;

6) 21 статьяның 2 өлешенә "дәүләт органнары" сүзләре алдыннан "Татарстан Республикасы" сүзләрен өстәргә;

7) 25 статьяның 3 пунктында "дәүләт яисә муниципаль хезмәткәрләрнең" сүзләрен "Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең, муниципаль хезмәткәрләрнең" сүзләренә алмаштырырга;

8) 30 статьяда:

а) 1 өлештә "Дәүләт органнары" сүзләре алдыннан "Татарстан Республикасы" сүзләрен өстәргә; "ярдәм итәргә" сүзләрен "ярдәм итәләр" сүзләренә алмаштырырга; "бирергә тиеш" сүзләрен "бирәләр" сүзенә алмаштырырга;

б) 2 өлештә "җибәрелергә тиеш" сүзләрен "җибәрелә" сүзенә алмаштырырга;

9) 32 статьяда "Дәүләт органнарының" сүзләре алдыннан "Татарстан Республикасы" сүзләрен өстәргә;

10) 34 статьяның 2 өлешен үз көчен югалткан дип танырга;

11) түбәндәге эчтәлекле $V^1$ бүлек өстәргә:

"$V^1$ бүлек. **Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил**

$35^1$ статья. **Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил вазыйфасын гамәлгә кую**

1. Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил (алга таба – Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил) вазыйфасы бала хокукларын дәүләт тарафыннан яклау гарантияләрен көчәйтү, аларны Татарстан Республикасы дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары һәм вазыйфаи затлар тарафыннан үтәүгә һәм ихтирам итүгә ярдәм күрсәтү максатларында гамәлгә куела.
2. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын били.
3. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Вәкаләтле вәкилнең урынбасары була.

$35^2$ статья. **Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил кандидатурасына карата таләпләр**

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил итеп 35 яшьтән дә яшь булмаган, югары һөнәри белеме һәм бала хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау өлкәсендә тәҗрибәсе булган Россия Федерациясе гражданы сайлана.

$35^3$ статья. **Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил вазыйфасына сайлау тәртибе**

1. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил вазыйфасына кандидатураны Татарстан Республикасы Дәүләт Советына Татарстан Республикасы Президенты тәкъдим итә.
2. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил үз вазыйфасына Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларының сайланган саныннан күпчелек тавыш белән Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан сайлана.

$35^4$ статья. **Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең вәкаләтләре срогы**

1. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил вазыйфасына биш ел срокка сайлана.
2. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил вәкаләтләре яңа Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил сайланган көннән туктатыла.
3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы вәкаләтләре срогы тәмамлану яисә аны тарату Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил вәкаләтләрен туктатуга китерми.

35[5] статья. **Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил өчен чикләүләр**

Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил Татарстан Республикасы дәүләт вазыйфасын биләүче затлар өчен билгеләнгән чикләүләрне федераль законнар нигезендә үтәргә тиеш.

35[6] статья. **Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилне вазыйфасыннан вакытыннан алда азат итү**

1. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил вазыйфасыннан әлеге Законның 12 статьясында күрсәтелгән очракларда һәм тәртиптә Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан вакытыннан алда азат ителә.

2. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил вәкаләтләре әлеге Законның 12 статьясындагы 1 һәм 2 өлешләрендә күрсәтелгән нигезләр буенча вакытыннан алда туктатылган очракта, яңа Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил сайланганчы, аның вәкаләтләрен Вәкаләтле вәкил башкара.

35[7] статья. **Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең вәкаләтләре**

1. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил:

1) Татарстан Республикасы дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының, вазыйфаи затларның балалар хокукларын бозуга китерә торган карарларына яисә гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләрне караганда катнаша һәм билгеләнгән компетенция чикләрендә алар буенча, гамәлдәге законнарга таянып, тиешле карарлар кабул итә;

2) шикаятьләр буенча тикшерүләр, шулай ук балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен бозуга кагылышлы мөрәҗәгатьләр буенча тикшерүләр үткәргәндә балаларның мәгариф учреждениеләрендә; мәгариф идарәсе органнарының ачык һәм ябык типтагы махсус укыту-тәрбия учреждениеләрендә; балаларга медицина ярдәме күрсәтә торган сәламәтлек саклау учреждениеләрендә; авыр тормыш хәлендә калган балалар өчен социаль приютларда; ата-ана каравыннан мәхрүм калган балаларга ярдәм үзәкләрендә; эчке эшләр органнарының хокук бозган балигъ булмаганнар өчен вакытлыча тоту үзәкләрендә каршылыксыз булырга һәм балаларны тоту шартларын өйрәнергә хокуклы;

3) бала хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү һәм яклау өлкәсендә Татарстан Республикасы норматив хокукый актларын әзерләүдә катнаша;

4) балаларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен яклау өлкәсендәге законнарны камилләштерү буенча Вәкаләтле вәкилгә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнарына тәкъдимнәр кертә;

5) Татарстан Республикасында бала хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү турындагы махсус докладын ел саен Татарстан

Республикасы Президентына, Татарстан Республикасы Дәүләт Советына, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына, Татарстан Республикасы Конституция судына, Татарстан Республикасы Югары судына, Татарстан Республикасы Арбитраж судына, Татарстан Республикасы Прокурорына җибәрә;

6) балаларның әхлакый һәм рухи сәламәтлегенә тискәре йогынты ясый торган хәлләрне билгеләү максатында басма, аудио- һәм видеопродукциягә мониторинг алып бара;

7) Вәкаләтле вәкил билгели торган вазыйфаларны бүлешү нигезендә Вәкаләтле вәкил урынбасары вәкаләтләрен башкара.

2. Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә әлеге Законның 2, 3, 30 – 35 статьяларының гамәли көче кагыла. Әлеге Законның 13 – 22, 25 статьяларының гамәли көче Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилгә бала хокукларына кагылышлы мәсьәләләр өлешендә генә кагыла.";

12) 36 статьяда:

а) 1 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"1. Вәкаләтле вәкилнең, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкилнең эшчәнлеген тәэмин итү һәм аларның үз вәкаләтләрен башкару өчен Вәкаләтле вәкил аппараты (алга таба – аппарат) төзелә.";

б) 2 өлештә "Вәкаләтле вәкил һәм аның аппараты" сүзләрен "Вәкаләтле вәкил, Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил һәм аппарат" сүзләренә алмаштырырга;

в) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"3. Аппарат хезмәткәрләре дәүләт граждан хезмәте турында Татарстан Республикасы законнары нигезендә Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренә кертелә.";

г) 4 өлешкә "Вәкаләтле вәкил" сүзләреннән соң ", Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил" сүзләрен өстәргә.

**2 статья**

Административ хокук бозулар турында 2006 елның 19 декабрендәге 80-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 12 (I өлеш); 2007, № 11; 2009, № 2; № 7 – 8 (I өлеш), № 9 – 10, № 12 (I өлеш); 2010, № 1 – 2; Ватаным Татарстан, 2010, 31 март, 2 апрель) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 2.3 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"2.3 статья. **Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлегенә каршылык күрсәтү**

Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлегенә аларның карарларына йогынты ясау максатында катышкан, "Татарстан

Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил турында" Татарстан Республикасы Законы белән билгеләнгән вазыйфаларны вазыйфаи затлар тарафыннан үтәмәгән, шулай ук Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил, Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил эшчәнлегенә бүтән рәвештә каршылык күрсәткән өчен –

бер меңнән алып ике мең сумга кадәр күләмдә административ штраф салына.";

2) 8.1 статьяның 3 өлешенә "Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча вәкаләтле вәкил" сүзләреннән соң", Татарстан Республикасында Бала хокуклары буенча вәкаләтле вәкил" сүзләрен өстәргә.

**3 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Татарстан Республикасы Президенты, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты үзләренең норматив хокукый актларын өч ай эчендә әлеге Законга туры китерергә тиеш.

Татарстан Республикасы
Президенты — Р.Н. Миңнеханов

ГОМУМИ БҮЛЕК
ОБЩИЙ ОТДЕЛ

Казан, Кремль
2010 елның 28 июне
№ 34-ТРЗ